ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2019 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы проектын нигездә кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар 2019 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планына искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне 2018 елның 26 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертергә тиеш.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты, закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлардан кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 2019 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планын 2018 елның 30 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2018 елның 19 ноябре
№ 2592-V ДС